РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12 февраль 2021 ел Буа шәһәре № 5-8

Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә аеруча зур өлеш керткән хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Буа муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә аеруча зур өлеш керткән хезмәт ветераннарына социаль ярдәм күрсәтү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфасында һәм җитәкче хуҗалык эшендә 25 ел эшләгән һәм җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы булган хезмәт ветераннарына торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә айлык акчалата түләүне башкарырга.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә бирү ярдәм итү чарасын алуның мәҗбүри шарты булып тора.

2. Түләүне Буа муниципаль районы бюджетыннан аена 130 сум исәбеннән башкарырга кирәк.

3. Буа район Советының 2006 елның 9 сентябрендәге 80-11 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан көненнән закон көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов